ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 Казан ш. № 507-135/кс-2022

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

«Куйбышев Затоны коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте тарафыннан салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә хезмәтләр күрсәтү буенча эшчәнлекнең җайга салынулы төрләрен гамәлгә ашыруны туктатуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 2022 елның 16 ноябрендәге 37-ПР номерлы беркетмәсе нигезендә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«2019 - 2023 елларга «Куйбышев Затоны коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте өчен эчәргә яраклы суга һәм ташландык су агызуга тарифлар билгеләү турында» 14.12.2018 № 10-163/кс;

«Куйбышев Затоны коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №10-163/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2020 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 20.11.2019 № 10-64/кс;

«Куйбышев Затоны коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №10-163/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2021 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 11.11.2020 № 207-64/кс-2020;

«Куйбышев Затоны коммуналь челтәрләре» ачык акционерлык җәмгыяте өчен эчә торган суга һәм ташландык су агызуга Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 14.12.2018 №10-163/кс карары белән билгеләнгән дәвамлы тарифларга 2022 ел өчен төзәтмә кертү хакында» 08.12.2021 № 467-134/кс-2021.

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев